**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
423740,село Актаныш, проспект Ленина, дом 58,тел.3-15-99

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКТАНЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
423740, Актаныш авылы, Ленин проспекты, 58 нче йорт, тел.3-15-99

# КАРАР

**25 июнь 2024 ел** № 8

**Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 4 өлешенә, Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге Уставына ярашлы рәвештә, Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы Советына Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетына Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге Башкарма комитетының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрен тапшыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт төзү һәм аның эшчәнлек тәртибен раслау;

җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләү.

2. Актаныш муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимнәрне кабул иткән очракта, Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге башкарма комитетына:

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

Әлеге карарны тормышка ашыруны тәэмин итү максатыннан, 2024 елга 2025 һәм 2026 еллар план чорына Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге бюджеты турында карарга үзгәрешләр кертү хакында Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге Советы карары проектын әзерләргә һәм бюджет законнары нигезендә карауга тапшырырга.

3. Әлеге карарны рәсми рәвештә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә игълан итәргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

5. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Актаныш авыл җирлеге башлыгы- Совет рәисе** Л.Р.Зарипов